КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 июнь г.Казань № 531

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 20 сентябь, 890 нчы карары белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаручы медицина оешмалары норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 ел, 20 сентябрь, 890 нчы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел,

27 декабрь, 1300 нче, 2022 ел, 08 апрель, 339 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаручы медицина оешмалары норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициентларына, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» юлында «1,173046» саннарын «1,215101» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин